**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 24 сентябрендәге 4025 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 мартындагы 1009 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль биремгә кертелмәгән чараларны оештыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 8 декабрендәге 4290 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы “Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 мартындагы 1009 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль

бюджет учреждениесенә муниципаль биремгә кертелмәгән чараларны оештыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар атамасында һәм 1 пунктта «Шәһәрне үстерү институты» сүзләрен «Казан шәһәрен үстерү институты» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль биремгә кертелмәгән чараларны оештыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибендә:

1.2.1. атамада һәм 1.1 пунктта «Шәһәрне үстерү институты» сүзләрен «Казан шәһәрен үстерү институты» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2.2. 2.1 пунктны «Идарәгә» сүзеннән соң «uag.kazan@tatar.ru электрон почтасы аша электрон документ рәвешендә яки 420012, Казан шәһәре, Груздев урамы, 5 йорт адресы буенча язма рәвештә» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2.3. 2.2 һәм 2.3 пунктларда тиешле килештәге «заявка» сүзен, тиешле килешкә куеп, «гариза» сүзе белән алмаштырырга;

1.2.4. 2.2 пунктның «б» пунктчасын «карап тикшерә» сүзләре алдыннан «өч эш көне эчендә» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2.5. 2.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Ачыкланган җитешсезлекләрне бетергәннән соң кабат кергән гаризаны карап тикшерү Идарә тарафыннан әлеге пункт белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакыт эчендә гамәлгә ашырыла»;

1.2.6. 4.3 пунктның беренче абзацында «, Идарә белән килештереп, Учреждение тарафыннан кабул ителә» сүзләрен «Идарә тарафыннан кабул ителә» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2.7. кушымтада «Шәһәрне үстерү институты» сүзләрен «Казан шәһәрен үстерү институты» сүзләре, «заявка» сүзен «гариза» сүзе белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**